ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
II СОЗЫВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
II ЧАКЫРЫЛЫШ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 июль, 2015 ел № 41/8

Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, 2006 елның 13 мартындагы «Реклама турында» 38-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсе, шәһәр Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 санлы Карары (Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/10, 2014 елның 17 апрелендәге 30/9, 2014 елның 10 июлендәге 31/17, 2014 елның 9 декабрендәге 35/10 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктта:

- 2 пунктчада «тышкы реклама һәм мәгълүмат» сүзләрен «реклама корылмалары һәм тышкы мәгълүмат чаралары» сүзләренә алыштырырга;

- 16 пунктчада «тышкы реклама һәм мәгълүмат чаралары» сүзләрен «реклама корылмалары һәм тышкы мәгълүмат чаралары» сүзләренә алыштырырга;

2) 14 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 бүлек. Реклама корылмалары һәм тышкы мәгълүмат чаралары»;

3) 119 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«119. Шәһәр территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру, эксплуатацияләү һәм сүтеп алу Россия Федерациясенең реклама

турында законнары, Шәһәр Советы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында Нигезнамә һәм әлеге Кагыйдәләр нигезендә башкарыла.»;

4) 120 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«120. Реклама корылмалары һәм тышкы мәгълүмат чаралары, аларны биналарда, корылмаларда урнаштырганда, биналарның, корылмаларның архитектурасына туры килергә һәм шәһәрнең, мәйданнарның, биналарның, корылмаларның бердәм тышкы күренешен бозмаска тиеш.

Тышкы мәгълүмат чараларын биналар фасадында урнаштыру вариантлары Башкарма комитет карары белән раслана.

Реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннары Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә килештерелгән реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын объектта урнаштыру концепциясе нигезендә билгеләнә.»;

5) түбәндәге эчтәлектәге 121.1 пунктын өстәргә:

«121.1. Газеталарны, афишаларны, плакатларны, белдерүләрне урнаштыру махсус стендларда гына рөхсәт ителә.»;

6) түбәндәге эчтәлектәге 121.2 пунктын өстәргә:

«121.2. Биналар фасадында, корылмаларның һәм киоскларның тышкы стеналарында, коймаларда, павильоннарда, яктырту терәкләрендә, реклама корылмаларында һәм тышкы мәгълүмат чараларында, агачларда һәм асфальтта белдерүләр һәм мәгълүмати хәбәрләр урнаштыру, шулай ук язулар һәм сурәтләр төшерү тыела.»;

7) түбәндәге эчтәлектәге 121.3 пунктын өстәргә:

«121.3. Электротранспорт, урамнарны яктырту терәкләрен, биналар цоколен, коймаларны һәм башка корылмаларны белдерүләрдән һәм мәгълүмати хәбәрләрдән арындыруны әлеге объектларны эксплуатацияләүче оешмалар башкара.

8) 53 бүлекне төшереп калдырырга;

9) 63 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«63 бүлек. Реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын карап тоту»;

10) 543 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«543. Реклама корылмалары һәм тышкы мәгълүмат чаралары техник яктан төзек һәм эстетик каралган булырга тиеш.

Реклама корылмасының, тышкы мәгълүмат чарасының хуҗасы аның тиешле техник һәм эстетик торышын күзәтеп торырга, вакытында төзекләндерергә, буярга һәм реклама корылмасы, тышкы мәгълүмат чарасы урнашкан урынны җыештырып торырга тиеш.

Реклама корылмасыннан мәгълүмат алынганда, реклама кыры ачык тоннардагы баннер тукымасы белән капланырга тиеш.

Реклама корылмасын, тышкы мәгълүмат чарасын урнаштыргач (сүтеп алгач), реклама корылмасының, тышкы мәгълүмат чарасының хуҗасы реклама корылмасы, тышкы мәгълүмат чарасы урнаштырылган урынны өч тәүлек эчендә төзекләндерергә тиеш.

Реклама корылмасы, тышкы мәгълүмат чарасы, нигез блогы булган очракта, нигез блогы белән бергә сүтеп алынырга тиеш.

Реклама корылмасын, тышкы мәгълүмат чарасын тиешенчә карап тотмаган өчен, реклама корылмасының, тышкы мәгълүмат чарасының хуҗасы җаваплы.»;

11) түбәндәге эчтәлектәге 543.1 пунктын өстәргә:

«543.1. Яктырту реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын эксплуатацияләүче оешмаларга көн саен тәүлекнең караңгы вакыты җиткәч, аларны кушарга һәм урамнарны яктыртуны аеру вакытында сүндерергә кирәк, ләкин көн яктырганнан соң түгел, янып чыккан элементларны вакытында алмаштыру зарур.

Реклама корылмасының, тышкы мәгълүмат чарасының аерым элементлары төзек булмаган очракта, тулаем бөтен реклама корылмасы, тышкы мәгълүмат чарасын сүндерергә кирәк.

Витриналарны махсус яктырту приборлары белән җиһазландыру зарур.»;

12) 544 пунктта:

- 2 пунктчада «тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларында» сүзләрен «реклама корылмаларында һәм тышкы мәгълүмат чараларында» сүзләренә алыштырырга;

- 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын тиешсез торышта карап тоту (яктыртылмау, кайбер яктырту элементларының эшләмәве, аерым хәрефләрнең һәм саннарның булмавы, буявы булмау, тутык булу, бозылган сурәт, сурәтнең булмавы; конструктив элементларның ватылуы)»;

- 4 пунтчада «тышкы реклама һәм мәгълүмат чаралары» сүзләрен «реклама корылмалары һәм тышкы мәгълүмат чаралары» сүзләренә алыштырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктчаны өстәргә:

«5) Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә алынган килештерүдән башка тышкы мәгълүмат чарасын урнаштыру»;

13) 545 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«545. Аерым торучы реклама корылмасы, тышкы мәгълүмат чарасы белән чиктәш, реклама корылмасыннан, тышкы мәгълүмат чарасыннан 5 м радиустагы территорияне җыештыру буенча эшләрне оештыру һәм һәм башкару өчен җаваплылык аның хуҗасына йөкләнә.»;

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының халык яшәешен тәэмин итү һәм шәһәр төзелеше буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме
вазифаларын башкаручы — Ф.И. Андреева